Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 март 2019 ел №281

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, районның социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән предприятие, учреждение, оешма коллективларын һәм гражданнарны бүләкләү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, җирле үзидарәне үстерү, хезмәт казанышларын, һөнәри осталыкны, фәнни һәм иҗади эштәге казанышларны тану, укуда, тәрбия һәм башка иҗтимагый-сәяси эшчәнлектә уңышлар өчен бүләкләү максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы бланк формасын расларга (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты бланк формасын расларга (3 нче кушымта).

4. Әлмәт муниципаль районы Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы турында» 2006 елның 19 маендагы № 73 карары;

- «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты турында» 2006 елның 19 маендагы № 74 карары.

5. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 25 мартындагы № 281
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты район үсешенә керткән хезмәт казанышларын, һөнәри осталыкны, фәнни һәм иҗади эштәге казанышларны, укудагы, тәрбия һәм башка иҗтимагый-файдалы эшчәнлектә уңышларны тану документы булып тора.

1.2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы,Рәхмәт хаты белән районның барлык тармакларында һәм социаль-мәдәни өлкәдә эшләүче хезмәткәрләр, инженер-техник хезмәткәрләр, студентлар, мәгариф, фән, сәнгать, әдәбият һәм башка өлкәләрдә эшләүчеләр, хәрби хезмәткәрләр һәм ветераннар, шулай ук бригадалар, экипажлар, сменалар, төркемнәр, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башкалар бүләкләнәләр.

1.3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты белән бүләкләү хезмәт коллективы яки конкрет зат, депутатлар, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары, авыл җирлекләре башлыклары, предприятие, оешма, учреждение хезмәт коллективлары җитәкчеләре тәкъдим итүе (үтенеч язуы) буенча башкарыла.

1.4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә предприятиенең эчке бүләкләре, оешмалар яки башка бүләкләре (аерым очраклардан тыш) булган затлар тәкъдим ителә.

1.5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты, предприятиенең эчке бүләкләре, оешмалар яки башка бүләкләре (аерым очраклардан тыш) булган затлар тәкъдим ителә.

1.6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты, Мактау грамотасы белән бүләкләү белән бүләкләү турындагы үтенеч язуында булырга тиеш:

- гражданнарны бүләкләү өчен: кыскача биографик мәгълүматлар һәм бүләкләүгә тәкъдим ителгән конкрет казанышлар күрсәтелгән характеристикалар;

- коллективларны бүләкләү өчен: оешма турында тулы исем һәм кыскача белешмә, коллективның конкрет казанышлары.

1.7. Бүләкләү турындагы үтенеч язуы Әлмәт муниципаль районы башлыгына тапшырыла.

1.8. Үтенеч язуы алдан карау һәм рәсмиләштерү, дөреслеген тикшерү өчен тапшыру көненә кадәр 30 көннән дә ким булмаган вакыт эчендә бирелә.

Билгеләнгән тәртип һәм тапшыру срокларын бозып рәсмиләштерелгән документлар каралмый.

1.9. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты, Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карары район башлыгы һәм район башкарма комитеты җитәкчесе карары (күрсәтмәсе) белән рәсмиләштерелә.

1.10. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты тексты ике дәүләт телендә рәсмиләштерелә һәм район башлыгы һәм район башкарма комитеты җитәкчесе карары текстына (күрсәтмәсенә) туры китерелә.

1.11. Гражданны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты, Мактау грамотасы белән бүләкләү турында хезмәт кенәгәсенә языла.

1.12. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты белән кабат бүләкләү, район алдында яңа казанышлары өчен алдагы бүләкләүдән соң 2 ел узгач кына мөмкин, район файдасына башкарылган искиткеч батырлыгы, кыюлыгы һәм каһарманлыгы өчен бүләкләү очракларыннан тыш.

1.13. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасын, Рәхмәт хатларын югалтканда дубликат бирелми.

## 2. Мактау грамотасы тасвирламасы

А3 форматындагы Мактау грамотасы тулы төсле басма ысул белән эшләнгән. Үзәк буенча ике А4 форматында урталай бөкләнә. Үзәктә чиктән 40 мм түбәнрәк Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы символы (гербы) сурәтләнгән.

Символдан 5 мм да (гербтан) түбәнрәк, 10 мм хәрефләр белән басылган «МАКТАУ ГРАМОТАСЫ» дигән сүзләр бер юлда урнашкан. "Мактау грамотасы" сүзеннән соң ике баскычка түбәнрәк «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ ҺӘМ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» дигән сүзләр 5 мм биеклектәге хәрефләр белән урнаштырылган.

10 мм дан түбәнрәк, ике юлга 5 мм биеклектәге хәрефләр белән «МАКТАУ ГРАМОТАСЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНӘЛӘР» сүзләре басылган.

Бит уртасында бүләкләнүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яисә район башлыгы һәм район башкарма комитеты җитәкчесенең, Мактау грамотасы белән бүләкләнүче юридик затның исеме һәм карарның кыскача тексты күрсәтелә.

15 мм га тексттан түбәнрәк Әлмәт муниципаль районы башлыгы һәм Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең имзалары куела.

Мактау грамотасы махсус папкада тапшырыла.

## 3. Рәхмәт хатлары тасвирламасы

А4 форматындагы Рәхмәт хаты тулы төсле басма ысулы белән эшләнгән. Үзәк буенча А5 форматында урталай бөкләнә. Үзәктә чиктән 25 мм га түбәнрәк Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы символы (гербы) сурәтләнгән.

Символдан 5 мм да (гербтан) түбәнрәк 5 мм хәрефләр белән басылган «РӘХМӘТ ХАТЫ» дигән сүзләр бер юлда урнашкан.

10 мм дан түбәнрәк, бер юлга 5 мм биеклектәге хәрефләр белән
«РӘХМӘТ БЕЛДЕРӘЛӘР» сүзләре басылган.

Бит уртасында бүләкләнүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яисә район башлыгы һәм район башкарма комитеты җитәкчесенең, Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән юридик затның исеме күрсәтелә.

15 мм га тексттан түбәнрәк Әлмәт муниципаль районы башлыгы һәм Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең имзалары куела.

Рәхмәт хаты махсус папкада тапшырыла.

## 4. Мактау грамоталарын, Рәхмәт хатларын тапшыру

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамотасын, Рәхмәт хатларын тапшыру тантаналы шартларда Әлмәт муниципаль районы башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлмәт муниципаль районы башлыгы кушуы буенча һәм аның исеменнән Мактау грамотасын, Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Рәхмәт хатын аның урынбасарлары, район Советы аппараты җитәкчесе, район (шәһәр) башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары, авыл җирлекләре башлыклары, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләре тапшыра ала.

Бүләкләү вакытында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамоталарын, Рәхмәт хатларын сәхнәгә бүләкләү төркеме чыгара (махсус костюмнарда район башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге хезмәткәрләре). Бүләкләү төркеме 4 кешедән тора.

## 5. Мактау грамотасын, Рәхмәт хатларын рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитетының Мактау грамоталарын, Рәхмәт хатларын рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 25 мартындагы № 281 карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Мактау грамотасы бланк формасы




Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 25 мартындагы № 281
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының һәм башкарма комитетының Рәхмәт хаты бланк формасы




Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин